РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОМЕНЗЕЛЯБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**30 гыйнвар 2025 ел** **№ 1**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Җирләү һәм җирләү эше турында" 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "2025 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында" 23.01.2025 № 33 карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Сарман муниципаль районы «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2025 елның 1 февраленнән 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 9 165,37 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында»гы 31.01.2024 ел, № 2 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru/

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе А.Н.Габдрахманов

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2025 елның 30 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2025 елның 1 февраленнән үлгән кешенең күмү бурычын үз өстенә алган хатынына (иренә), якын туганнарына, башка туганнарына, законлы вәкилгә яисә башка затка җирләү эше буенча махсуслаштырылган хезмәт күрсәтә торган гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4 070,37 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1 800,00 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 295,00 |
| Барлыгы | 9 165,37 |

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесенең
2025 елның 30 гыйнварындагы 1
номерлы карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2025 елның 1 февраленнән үлгән кешенең хатыны (ире), якын туганнары, башка туганнары яки законлы вәкиле булмаган яки җирләү мөмкин булмаган очракта, шулай ук эчке эшләр органнары аның шәхесен билгеләгәннән соң,өйдә, урамда яки башка урында үлгән кешене җирләү бурычын үз өстенә алган башка кешеләр булмаганда, җирләү эше буенча махсуслаштырылган хезмәт күрсәтә торган гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе-(сум.) |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Кәфенләү | 1 500,00 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 570,37 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1 800,00 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 295,00 |
| Барлыгы | 9 165,37 |